СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423181, РТ Новошешминский район с. Ленино, ул. 40 лет Победы д. 32

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423181 РТ Яңа Чишмә районы ,Ленино авылы, Җиңүнең 40еллыгы урамы, 32

тел.: (8-4348) 3-44-16, факс: (8-4348) 3-44-10; Lenin.nsm@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

“14” нче ноябрь 2018 нче ел №53-101

**“Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 12 нче ноябрендәге “Җир салымы турында” 19-39 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында”**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы “Ленино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советы 12.11.2016 №19-39

**КАРАР БИРӘ:**

I. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 12 нче ноябрендәге «Җир салымы турында» гы 19-39 нчы номерлы карарына (2017 нче елның 8 нче сентябрендәге 33-68 нче номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 12 нче ноябрендәге “Җир салымы турында” 19-39 нчы номерлы карарының 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Салым ташламалары бирергә:

3.1. шәхси торак йортлар, шәхси ярдәмче хуҗалык, гараж һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә җир салымын түләүдән, кануннарда каралган салым түләүчеләр категорияләреннән тыш, түбәндәге салым түләүчеләргә - физик затлар категориясенә дә азат итү рәвешендә:

- ялгызлыкта яшәүче 75 яшьтән өлкәнрәк яшьтәге гражданнар;

- ятим балалар;

- табигый бәла-казалардан зыян күргән гражданнар;

- Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, шулай ук сугыш хәрәкәтләре ветераннары һәм инвалидлары;

- янгын сагы җәмәгать берләшмәләре һәм иректе янгын сүндерүчеләр әгъзалары.

3.1.пунктында санап үтелгән салым түләүчеләр категориясенә керә торган һәм Ленино авыл җирлеге территориясендә берничә җиркишәрлеге (өлешләр) булган) физик затларга салым ташламасы салым түләүченең теләге буенча бары тик бер җир кишәрлеге (өлеш) өчен генә бирелә.

3.2. салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә 100% күләмендә җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә:

- оешмалар һәм учреждениеләрнең гражданнар күмелгән җир кишәрлекләренә карата".

II. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм физик затларның җир салымын исәпләүгә бәйле хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла, ләкин рәсми басылып чыкканнан соң бер айдан да иртәрәк түгел.

III. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында " бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru «Интернет»мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru .

IV. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Ленино авыл
җирлеге башлыгы В.М.Веретенников